ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» августа 2026 ел № 212

«2026-2027 елларга Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 25 маендагы 136 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында» 2010 елның 17декабрендәге 1050 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2024 елның 11 октябрендәге 877 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2027 елларга Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 25 маендагы 136 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган «2026-2027 елларга Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасының «Программаны гамәлгә ашыру механизмы» IV бүлегенең икенче абзацын (алга таба - муниципаль программа) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшь гаиләгә торак урын сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалануның «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт

программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре (алга таба - Яшь гаиләләргә торак сатып алуга (торак төзүгә) социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләре) нигезендә бирелә һәм файдаланыла;

1.2. Карар белән расланган "Муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы" IV бүлегенең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне билгеләү өчен, торак сатып алуга (төзүгә) кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) буенча алынган өстәмә акчаларның яисә акчаларның булуына, шул исәптән ипотека торак шартнамәсе буенча, торак урын төзү яисә сатып алу өчен кирәкле булган торак шартнамәсенә таянып, яшь гаиләләргә торак сатып алуга һәм алардан файдалануга социаль түләүләр бирү кагыйдәләрендә китерелгән документлар исемлегенә таянып эш итәләр;

1.3. Муниципаль программадан 1 нче, 2 нче һәм 3 нче кушымталарны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**